Хокукый акт проекты буенча гавами тыңлаулар башлану турында

ХӘБӘР ИТҮ

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының «Багай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар башлануы турында хәбәр итәбез

Проектка мәгълүмати материаллар исемлеге:

1. Шәһәр төзелеше регламентлары;
2. Шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы;
3. Территориядән файдалануның махсус шартлары булган зоналар чикләре картасы;
4. Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрен куллану һәм күрсәтелгән кагыйдәләргә үзгәрешләр кертү тәртибе.

Проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү тәртибе һәм сроклары:

1. Гавами тыңлауларга чыгарылган мәсьәләнең асылы буенча чыгышлар.
2. Гавами тыңлауларда катнашучыларның сорауларын һәм тәкъдимнәрен карау.

Гавами тыңлауларда катнашучылар чыгыш ясаучыларга барлык чыгышлар тәмамланганнан соң сораулар бирергә хокуклы. Сораулар һәм тәкъдимнәр язма рәвештә бирелә. Гавами тыңлаулар үткәрү срогы 2024 елның 03 декабреннән 2024 елның 17 декабренә кадәр.

Гавами тыңлауларда катнашучылар даирәсе: Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты, җир кишәрлеге урнашкан территориаль зона чикләрендә даими яшәүче гражданнар, шушы территориаль зона чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләренең һәм (яисә) аларда урнашкан капиталь төзелеш объектларының хокук ияләре, җир кишәрлеге чикләрендә даими яшәүче гражданнар, шундый җир кишәрлекләренең яисә аларда урнашкан капиталь төзелеш объектларының хокук ияләре, капиталь төзелеш объектының бер өлеше булган биналарның хокук ияләре.

Ачык тыңлауларда каралырга тиешле проект экспозициясен (экспозицияләрен) ачу урыны һәм датасы: Кайбыч районы, Олы Кайбыч ав., Кояшлы бульвар, 7 й., 2нче кат, 209 нчы кабинет адресы буенча урнашкан Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге.

Экспозициягә (экспозицияләргә) бару мөмкинлеге булган көннәр һәм сәгатьләр турында мәгълүмат: 2024 елның 3 декабреннән - 2024 елның 17 декабренә кадәр эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә хәтле.

Проектка кагылышлы тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне гавами тыңлауларда катнашучылар тарафыннан кертү тәртибе, сроклары һәм рәвеше: Кайбыч районы, Олы Кайбыч ав., Кояшлы бульвар, 7 й., 2 кат, 209 нчы кабинет адресы буенча урнашкан Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлегендә 2024 елның 03 декабреннән 2024 елның 17 декабренә кадәр язма рәвештә кабул ителә.

Гавами тыңлауларда катнашучылар җыелышын уздыру датасы, вакыты һәм урыны турында мәгълүмат: 2024 елның 17 декабрендә 10.00 сәгатьтә Кайбыч районы, Олы Кайбыч авылы, Кояшлы бульвар, 7 йорт адресы буенча урнашкан Иҗтимагый үзәк бинасының актлар залында.

Гавами тыңлауларда каралырга тиешле проект һәм аңа карата мәгълүмати материаллар урнаштырылган рәсми сайт турында мәгълүмат: Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтының «Башкарма комитет карарлары» бүлегендә (http://kaybici.tatarstan.ru).

Әлеге хәбәрне Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында «Сайтка керүчеләр өчен файдалы мәгълүмат» бүлегендә (http://kaybici.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru/) һәм Кайбыч районы, Олы Кайбыч авылы, Кояшлы бульвар, 7 йорт адресы буенча урнашкан Иҗтимагый үзәк бинасының һәм Кайбыч районы, Багай авылы, Үзәк ур., 28 й. адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Башкарма комитеты Җитәкчесе А.Н. Макаров